**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№ 27 от 30.12.2020г.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында яңа редакциядәге нигезләмә хакында» 24.08.2018 ел, № 158 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 13.11.2020 ел, 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында яңа редакциядәге нигезләмә хакында» 24.08.2018 ел, № 158 карары белән расланган) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 28 бүлекнең 28.10 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе, яисә хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр, шулай ук кирәк булганда, муниципаль хезмәт стажын раслый торган һәм әлеге Нигезләмәнең 30 бүлегендә күрсәтелгән башка документларның күчермәләре;».

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы сайтында интернет челтәрендә урнаштыру: http://aksubayevo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат порталында бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru

3. Карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы Башлыгы
Совет Рәисе К.К.Гилманов